# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ

## Боерык

«26» декабрь 2016 ел Казан шәһәре № 841

Регионнардагы иҗтимагый оешмаларга
яки гомумроссия спорт федерациясенең
структур бүлекчәләренә (регионнардагы
бүлекчәләренә) республика спорт
федерациясе статусын бирү өчен дәүләт
аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең
административ регламентын
раслау турында

2007 елның 4 декабрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә физик тәрбия һәм спорт турында» 329-ФЗ номерлы Федераль законының 13 маддәсенең 5 өлеше, Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2014 елның 1 августында кул куелган «Регионнардагы иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәләренә (регионнардагы бүлекчәләре) регоннардагы спорт федерациясе статусын бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү тәртибен һәм регионнардагы спорт федерациясе статусы барлыгын раслый торган дәүләт аккредитациясе турында документның формасын раслау турында» 663 номерлы боерыгы нигезендә

**боерам:**

1. Теркәлгән регионнардагы иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәләренә (регионнардагы бүлекчәләре) республика спорт федерациясе статусын бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламентын расларга.
2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2014 елның 24 ноябрендә кул куелган 845 номерлы «Республика спорт федерацияләренә дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгын гамәлдән чыккан дип санарга.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары Х.Х.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының 2016 елның
26 декабрендә кул куелган
841 номерлы боерыгы
тарафыннан
РАСЛАНГАН

**Регионнардагы иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәләренә (регионнардагы бүлекчәләренә) республика спорт федерациясе статусын бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең**
**административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент регионнардагы иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәләренә (регионнардагы бүлекчәләре) республика спорт федерациясе статусын бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: регионнардагы иҗтимагый оешма – юридик зат; гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәсе (регионнардагы бүлекчәсе) (алга таба – Гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: 420107, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Петербург урамы, 12 йорт.

Министрлыкның эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән кала, һәр көнне, 9:00 дан 18:00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты – 12:30 дан 13:30 кадәр.

Җәмәгать транспорты:

- 8, 10, 10а, 30, 35, 35а, 48, 54, 63, 65, 71, 83, 90, 91, 99а номерлы автобуслар
- 7, 17, 19, 20, 21 номерлы троллейбуслар белән «Бөҗрә» тукталышына,
- метро белән «Тукай мәйданы» станциясенә кадәр килергә.

1.3.2. Спорт төрләрен үстерү бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә өчен телефоннары: (843)222-81-46(48).

1.3.3. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайты адресы (алга таба – «Интернет» челтәре): http://mdms.tatarstan.ru, электрон почта адресы: mdms@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәге юллар белән алырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша.

Мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (подпунктларында) булган белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://mdms.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында: (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән (телефон буенча яки шәхсән) мөрәҗәгать итү аша;

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать (шул исәптән электрон документ рәвешендә) аша.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясе Салым кодексы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2000 ел, № 32, 3340 маддә);

2007 елның 4 декабрендә кул куелган «Россия Федерациясендә физик тәрбия һәм спорт турында» 329-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 329-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2007 ел, №50, 6242маддә; 2008 ел, № 30 (2 кисәк), 3616 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә);

2010 елның 27 июлендә кул куелган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010 ел, №31, 4179 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә);

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маенда кул куелган «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 601 номерлы Указы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012 ел, № 19, 2338 маддә);

Россия Федерациясе Финанслар министрлыгы Федераль казначылыгының 2012 елның 30 ноябрендә кул куелган «Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт һәм мәгълүмати системаны алып бару тәртибен раслау турында» 19н номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2015 елның 30 мартында кул куелган «Гомумроссия һәм регионнардагы аккредитацияләнгән спорт федерацияләренең реестрын алып бару һәм әлеге реестрда булган мәгълүматларны бирү тәртибен раслау турында» 276 номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, 2015 елның 18 июне, бастырып чыгару номеры **0001201506180029**);

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2014 елның 1 августында кул куелган «Регионнардагы иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәләренә (регионнардагы бүлекчәләре) республика спорт федерациясе статусын бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибен һәм регионнардагы спорт

федерациясе статусы барлыкныраслый торган дәүләт аккредитациясе турында документ формасын раслау турында» (алга таба – Тәртип) 663 номерлы боерыгы («Российская Газета» – Федераль чыгарылышның 6477 нче саны, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендә кул куелган «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 315 номерлы карары тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турында нигезләмә (Татарстан Республикасы карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 10.08.2005, № 30, 0695 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кул куелган 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 6 апрелендә кул куелган «Региондардагы иҗтимагый оешмаларга республика спорт федерацияләре статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча Комиссия төзү турында» 225 номерлы боерыгы тарафыннан расланган региондардагы иҗтимагый оешмаларга республика спорт федерацияләре статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча комиссия турында нигезләмә (Министрлыкның рәсми сайты (http://mdms.tatarstan.ru/), «Татарстан Республикасы спорт федерацияләре» бүлеге).

1.5. Спорт төре буенча дәүләт аккредитациясе түбәндәге очракларда игълан ителә:

а) Гариза бирүче спортның тиешле төре буенча региондардагы спорт федерациясе булмаган очракта Спорт төрләре бөтенроссия реестрының (алга таба – СТБР) беренче бүлегенә кертелгән спорт төрләре – спортның танылган төрләре (хәрби-гамәли, гамәли хезмәт, шулай ук гомумроссия дәрәҗәсендә үстерелә торган спорт төрләреннән тыш), СТБРның икенче бүлегендәге – гомумроссия дәрәҗәсендә үстерелә торган спорт төрләре, СТБР өченче бүлегенә кертелгән спортның милли төрләре буенча дәүләт аккредитациясе игълан итүне сорап мөрәҗәгать иткән чакта;

б) спортның тиешле төре буенча республика спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булу вакыты чыкканда;

в) республика спорт федерациясенең спортның тиешле төре буенча республика спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдән чыгу көненә кадәр 4 айлап вакыт калып барганда дәүләт аккредитациясен игълан итү

өчен Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә.

1.6. Татарстан Республикасы территориясендә спортның бер төре буенча Министрлык тарафыннан бары тик бер генә республика спорт федерациясе аккредитацияләнергә мөмкин.

1.7. Республика спорт федерацияләренә дәүләт аккредитациясе дүрт елдан да артмаган вакытка тормышка ашырыла.

1.8. Гариза бирүченең вәкиле – үз вәкаләтләре кысаларында яисә закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тутырылган ышаныч язуы нигезендә Гариза бирүче исеменнән эш итүче.

1.9. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм бәяләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелеп, документка кертелгән мәгълүматларның (дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе) мәгълүмат нигезендә документларга кертелгән мәгълүматлар белән туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтә урнашкан эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләр белән документларны кабул итү һәм тапшыру, консультация бирү буенча эш алып бара торган тәрәзә.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) буларак дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорау кабул ителә (2010 елның 27 июлендә кабул ителгән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 2 пункты). Гаризаның тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентның 2нче кушымтасында бирелде.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартының атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Регионнардагы иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия иҗтимагый федерацияләренед структур бүлекчәләрен (регионнардагы бүлекчәләрен) регионнардагы иҗтимагый оешмаларына республика спорт федерацияләре статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү | 329-ФЗ номерлы федераль закон; Тәртип |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы | 329-ФЗ номерлы федераль законның 13 маддәсенең 5нче пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен сурәтләү | Министрлыкның регионнардагы иҗтимагый оешмага яки гомумроссия иҗтимагый федерациянең структур бүлекчәсенә (регионнардагы бүлекчәләренә) спортның тиешле төре буенча дәүләт аттестациясе үткәрү һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү турындагы боерыгы.<br>Республика спорт федерациясе статусы Министрлык тарафыннан регионнардагы иҗтимагый оешмага яки гомумроссия иҗтимагый федерациянең структур бүлекчәсенә (регионнардагы бүлекчәләренә) спортның тиешле төре буенча дәүләт аттестациясе үткәрү һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү турындагы боерык чыгарган көннән башлап гамәлдә булган дип санала.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат. | Тәртипнең 11, 13нче пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген истә тотып, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты; әгәр туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты | Дәүләт аккредитациясен игълан итү турында боерык әлеге Регламентның 1.5 пунктында каралган шартлар килеп чыккан көннәр алып 10 эш көне дәвамында чыгарыла.<br>Дәүләт аккредитациясе үткәрү турында гаризалар бирү вакыты дәүләт аккредитациясен игълан итү турында боерыкка кул куелган көннән алып 20 эш көненнән дә кимрәк һәм 40 эш көненнән дә артыграк була алмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хат әлеге Регламентның 2.9 пункты тарафыннан каралган шартлар барлыкка килгән көннән алып биш эш көне дәвамында Гариза бирүчегә җибәрелә.<br>Региннардагы иҗтимагый оешмага яки гомумроссия иҗтимагый федерациянең структур бүлекчәсенә (региннардагы бүлекчәләренә) дәүләт аттестациясе үткәрү һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү турында яки дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында карар Министрлыкның дәүләт аккредитациясен игълан итү турындагы карары тарафыннан билгеләнгән Гариза бирүченең документларны бирү вакыты чыккан көннән алып 40 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә.<br>Дәүләт аккредитациясе узу турындагы документны (таныклыкны) бирү Министрлык тарафыннан РФ Спорт министрлыгының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында гомумроссия һәм аккредитацияләнгән региннардагы спорт федерацияләре реестрына (алга таба – Реестр) республика спорт федерациясе турында мәгълүмат кертү турында РФ Спорт министрлыгы боерыгы урнаштырылган көннән алып 15 эш көне эчендә тормышка ашырыла. | Тәртипнең 3нче пункты<br><br>Тәртипнең 6нчы пункты<br><br>Тәртипнең 11нче пункты<br><br>Тәртипнең 10нчы пункты<br><br>Тәртипнең 17нче пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт аккредитациясе турындагы документны (таныклыкны) яңадан рәсмиләштерү дәүләт аккредитациясе турындагы документны (таныклыкны) яңадан рәсмиләштерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны теркәгән көннән алып 10 эш көне дәвамында тормышка ашырыла.<br>Дәүләт аккредитациясен узуны раслый торган документның (таныклыкның) дубликатын бирү дәүләт аккредитациясен узуны раслый торган документның (таныклыкның) дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәтен бирү турында гаризаны теркәгән көннән алып 30 эш көне дәвамында тормышка ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | Тәртипнең 21нче пункты<br><br>Тәртипнең 19нчы пункты |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар тарафыннан каралган, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булган хезмәтләр өчен Гариза бирүче тәкъдим итәргә тиешле мәҗбүри документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан, шул исәптән электрон формада да, аларны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | 1. Дәүләт аккредитациясен алу өчен түбәндәге документлар кирәк:<br>а) регионнардагы иҗтимагый оешманы аккредитацияләү турында гариза;<br>б) регионнардагы иҗтимагый оешма Уставының күчермәләре (бер күчермә нотариаль тәртиптә расланган булырга тиеш) һәм, әгәр регионнардагы иҗтимагый оешма юридик зат түгел икән, гомумроссия спорт федерациясенең даими рәвештә эшләп килүче идарә органыннан алынган регионнардагы иҗтимагый оешманың гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәсе булып торуы турында, шулай ук аның урнашкан урыны һәм регионнардагы иҗтимагый оешманың җитәкче органнары турындагы мәгълүматны күрсәткән белдерү хаты;<br>в) регионнардагы иҗтимагый оешма әгъзалары булып торган затлар исемлеге (әлеге Регламентның 3нче кушымтасы);<br>г) регионнардагы иҗтимагый оешма җитәкче органнарының | 329-ФЗ номерлы Федераль законның 17 маддәсенең икенче өлеше 3, 4, 5 нче пунктлары; Тәртипнең 7нче, 8нче пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | аерым исемлеге турында мәгълүмат (әлеге Регламентның 4нче кушымтасы);<br>д) регионнардагы иҗтимагый оешма тарафыннан расланган:<br>оештыру съезды (конференциясе) яки иҗтимагый оешма төзү, аның уставын раслау һәм җитәкче органнарын һәм тикшерү-ревизия органын булдыру турындагы җыелыш беркетмәсе;<br>коммерциячел булмаган оешмага дәүләт теркәве уздыру турында таныклык күчермәләре;<br>е) иҗтимагый оешмасына СТБРның икенче бүлегенә кертелгән – гомумроссия дәрәҗәсендә үстерелә торган спорт төрләре һәм СТБР өченче бүлегенә кертелгән спортның милли төрләре буенча дәүләт аккредитациясе үткәрүне гомумроссия спорт федерациясе белән язмача килештерү (спортның тиешле төре буенча гомумроссия спорт федерациясе булган очракта);<br>ж) регионнардагы иҗтимагый оешманың гомумроссия спорт федерациясендә әгъза булып торуын раслый торган документ күчермәсе (спортның тиешле төре буенча гомумроссия спорт федерациясе булган очракта);<br>з) аларны регионнардагы иҗтимагый оешма үсешен тәэмин итә торган спорт төре буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасы составына кертү өчен спортчыларны сайлау тәртибен регламентлый торган документ проекты;<br>и) дәүләт аккредитациясе өчен беренче тапкыр документ бирә торган регионнардагы иҗтимагый оешмалар яки спорт төрен (төрләрен) үстерү программасын тормышка ашыру вакыты чыкканн региональ спорт федерацияләре өчен кимендә дүрт ел вакыт аралыгына спорт төрен (төрләрен) үстерү буенча планлаштырылган чаралар һәм хәзерге көнгә анализны үз эченә | |

| | | |
|---|---|---|
| | алган туры килә торган спорт төрен (төрләрен) үстерү программасы проекты;<br>дәүләт аккредитация уздыру моментына спорт төрен (төрләрен) үстерү программасын тормышка ашыру вакыты узмаган регионнардагы спорт федерацияләре өчен – узган вакыт аралыгында тормышка ашырылган чараларны исәпкә алып, төзәтмәләр кертү проекты белән спорт төрен (төрләрен) үстерү программасы күчермәсе;<br>к) регионнардагы иҗтимагый оешма эшчәнлеген финанслау чыганаклары, уздырылган төп чаралар, Татарстан Республикасы спорт җыелма командасының үсешен регионнардагы спорт федерациясе тормышка ашыра торган спорт төре буенча Россия чемпионатларында һәм беренчелекләрендә чыгыш ясау нәтиҗәләре турында белешмә;<br>л) гариза бирү көненнән алда бер ел эчендә регионнардагы иҗтимагый оешма уздырган спорт ярышлары беркетмәләренең һәм әлеге пунктта каралган документларның күчермәләре.<br>1 пунктның «б» - «ж» подпунктларында карлган белешмә һәм документлар кәгазьдә – ике, шулай ук электрон рәвештә бер нөсхәдә тапшырылалар.<br>2. Дәүләт аккредитациясе турындагы документ дубликатын бирү өчен:<br>а) дәүләт аккредитациясе турындагы документ дубликатын бирү турында гариза.<br>3. Дәүләт аккредитациясе турындагы документны яңадан теркәү өчен:<br>а) дәүләт аккредитациясе турындагы документны яңадан теркәү турында гариза; | |

| | | |
|---|---|---|
| | б) устав күчермәсе;<br>с) коммерциячел булмаган оешманы дәүләт теркәве турында таныклык;<br>г) дәүләт аккредитациясе турында элек бирелгән документ.<br>Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын Гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итеп ала ала. Гаризаның электрон формасы министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аның белән бергә бирелә торган документлар кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе буенча бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш йөртүче зат тарафыннан);<br>тапшырылуы турында белдерү хезмәтен кулланып почта аша заказлы хат ярдәмендә.<br>Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми кулланылышта булган мәгълүмати- телекоммуникация челтәрләре аша, шулай ук «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәк булган һәм Гариза бирүче | 1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе)<br>2. Дәүләт аккредитациясе турында документ бирү өчен дәүләт пошлинасы түләүне раслый торган документ (Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе). | Тәртипнең 7 пунктының «а» подпункты |

| | | |
|---|---|---|
| бирергә хокукы булган документларының тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны гариза бирүче тарафыннан шул исәптән турыдан-туры, андый мөмкинлек булса, электрон формада да алынырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны бирмәве гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче бирергә хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм бирү тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда саналган документларны таләп итү тыела. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актларда каралган очракларда килештерү таләп ителә һәм дәүләт хезмәте күрсәтә торган башкарма хакимият органы тормышка ашыра торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структура бүлекчәләре исемлеге | Килештерү каралмаган. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә кергән документны бирмәү.<br>2. Әлеге Регламентның 2.4 пунктының 2 графасындагы 2 абзацында күрсәтелгән гариза һәм документларны тапшыру вакытын бозу. | Тәртипнең 9нчы пункты |
| 2.9. 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә аңардан баш | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булып | 329-ФЗ Федераль законының 13нче |

| | | |
|---|---|---|
| тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | түбәндәгеләр тора:<br>1. Регионнардагы иҗтимагый оешма тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүмат булу.<br>2. Регионнардагы иҗтимагый оешманың 2007 елның 4 декабрендә кул куелган «Россия Федерациясендә физик тәрбия һәм спорт турында» 329-ФЗ номерлы Федераль законның 13нче маддәсенең 8 өлеше тарафыннан регионнардагы спорт федерацияләренә куелган таләпләргә туры килмәве.<br>3. Регионнардагы иҗтимагый оешма тарафыннан регионнардагы спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе көчен туктату өчен нигез булып торган бозуларны юкка чыгармау (әлеге Регламентның 2.5 пункты тарафыннан каралган гариза, мәгълүматлар һәм документлар моңа кадәр дәүләт аккредитациясе көче туктатылган регионнардагы иҗтимагый оешма тарафыннан бирелгән очракта).<br>3. Аккредитация<br>Аккредитация буенча органның шул ук спорт төренең үсешен тәэмин итүче башка регионнардагы иҗтимагый оешманың дәүләт аккредитациясе турында карар кабул итүе (ике яки аннан артыграк иҗтимагый оешмалар тапшырган әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган гаризалар, белешмәләр һәм документларны карау нәтиҗәләре буенча).<br>Регионнардагы иҗтимагый оешманың дәүләт аккредитациясеннән баш тарту очрагында андый оешма, баш тарту өчен нигез булып торган сәбәпләрне юкка чыгарганнан соң, дәүләт аккредитациясен игълан итү өчен Министрлыкка яңадан мөрәҗәгать итә ала, әмма Министрлыкның әлеге | маддәсенең 8нче өлеше,<br>Тәртипнең 14нче, 15нче пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | регионнардагы иҗтимагый оешманың дәүләт аккредитациясеннән баш тарту турында карар кабул иткән көннән соң бер елдан да азрак вакыт узмаган булырга тиеш (әлеге Регламентның 4 подпунктында каралган очрактан тыш). | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәп | Дәүләт аккредитациясен узу турында документ (таныклык) бирү республика спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында документ (таныклык) биргән өчен 5 000 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләгәннән соң башкарыла.<br>Дәүләт аккредитациясе узуны раслый торган документ (таныклык) дубликатын бирү дәүләт аккредитациясен раслый торган документ (таныклык) дубликатын биргән өчен 350 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләгәннән соң башкарыла.<br><br>Республика спорт федерациясе тарафыннан дәүләт аккредитациясен узу турында документ (таныклык) һәм дәүләт аккредитациясен узуны раслый торган документ (таныклык) дубликатын биргән өчен дәүләт пошлинасы түләү өчен реквизитлар:<br>Федераль казначылыкның ТР буенча идарәсе (Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы шәхси/сч 04112001180)<br>ИНН/КПП 1655043416/165501001<br>Татарстан Республикасы Милли банкы Казан ш. Бүлекчәсе<br>Исәп-хисап/с 40101810800000010001<br>БИК 049205001<br>КЕРЕМ КОДЫ 719.10807340011000.110<br>ОКТМО 92701000 | Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 маддәсенең 1 өлешенең 73, 77 нче пунктлары,<br>Тәртипнең 17нче, 19нчы пунктлары. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәп. | Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтүләр таләп ителми. | |
| 2.12.Дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорау биргән вакытта һәм шундый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Аккредитация алу өчен кәгазьгә язылган гариза тапшыру чират булган очракта 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алган чакта чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират тору билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маенда кабул ителгән 601 номерлы Указы |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, сорап язган гаризаны теркәү вакыты | Гариза кергән көнне. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуларын тәэмин итүгә, шундый хезмәтләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәк булган мебель, мәгълүмати стендлар белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз килүе (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аларның чикләрендә күчеп йөрү) тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиялы мәгълүмат инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | ТР МК 880 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиялы мәгълүматны урнаштыру һәм бизәүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгән вакытта вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте алуның дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләрне дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге. | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>бинаның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документларны кабул итә торган бүлмәләрнең кирәк кадәр санда булуы;<br>документлар кабул ителә һәм бирелә торган биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә Министрлыкның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакыт аралыгы турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1. гаризаларны кабул итү һәм карау вакытларын саклау;<br>2. дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакыты саклану;<br>3. дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан җибәрелгән Административ регламентны бозуларга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>4. гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара тәэсир итешү саны:<br>гаризаны турыдан-туры биргән вакытта – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча); | |

| | | |
|---|---|---|
| | гаризаны һәм документларны почта аша яки электрон рәвештә юллаган очракта – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Гариза бирүче белән үзара тәэсир итешүнең дәвамлылыгы – 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлыкка мөрәҗәгать иткән чакта алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте (шул исәптән дәүләт хезмәтен бирү турында гариза бирү) күпфункцияле үзәктә, КФҮнең читтә урнашкан эш урыны аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче http://mdms.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында ала ала. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми.<br>Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны бирү тәртибе турында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша консультация үткәрү мөмкинлеге бар. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелек һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формадагы административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтә урнашкан эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткән чактагы административ гамәлләрнең сурәтләү һәм эзлеклелек.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәге административ процедураларны ала:

1) Гариза бирүчегә ярдәм күрсәтүне күз алдында тота торган консультация бирү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү;

2) дәүләт аккредитациясе игълан итү өчен мөрәҗәгатьләрне кабул итү һәм теркәү;

3) регионнардагы иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясен игълан итү турында боерык бастырып чыгару;

4) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

5) алар карамагында дәүләт ярдәме күрсәтү өчен кирәк булган документлар булган органнарга ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү бердәм системасы (алга таба – ВЭХБС) аша ведомствоара сораулар формалаштыру һәм җибәрү;

6) республика иҗтимагый оешмаларына республика спорт федерациясе статусы бирү өчен Дәүләт аккредитациясе буенча комиссия утырышын уздыру, Аккредитация буенча комиссия утырышын уздыру турында беркетмә төзү;

7) регионнардагы иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү турында яки дәүләт аккредитациясеннән баш тарту турында карар кабул итү;

8) Россия Федерациясе Спорт министрлыгына республика спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе турында белешмәләр һәм документлар тапшыру, Гариза бирүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

9) дубликатлар бирү һәм дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклык) яңадан теркәү;

10) техник хаталарны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентның 6 нче кушымтасында тәкъдим ителде.

3.2. Гариза бирүчегә ярдәм күрсәтүне күз алдында тота торган, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны тутыру өлешендә, консультация бирү.

Бүлек белгече Гариза бирүчегә шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында, Гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен алу өчен кирәк булган документларны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтүне күз алдында тота торган дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирүне тормышка ашыра.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнеп куела торган процедура Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне, яки электрон почта аша мөрәҗәгать иткән вакыттан башлап өч эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу өчен кирәк булган документациянең составы һәм эчтәлеге буенча консультация, Гариза бирүчегә документларны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.3. Регионнардагы иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе игълан итү буенча мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү, Гариза бирүчегә консультация бирү.

3.3.1. Гариза бирүченең вәкиле язмача, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон формада яки тапшырылуы турында белдерү хезмәтен кулланып почта аша заказлы хат ярдәмендә регионнардагы иҗтимагый оешмага спортның тиешле төре буенча дәүләт аккредитацияләвен игълан итүне сорап мөрәҗәгать юллый.

3.3.2. Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Мөрәҗәгатьне терки һәм үтәү өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар Гариза бирүчедән Мөрәҗәгать кергән көнне үк тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: теркәлгән Мөрәҗәгать.

3.4. Регионнардагы иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясе игълан итү турында боерык бастырып чыгару.

3.4.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать нигезендә регионнардагы иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясен игълан итү турында боерык (алга таба – Боерык) проекты әзерли. Биредә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында гаризалар бирү вакыты әлеге Боерыкка кул куелган көннән алып 20 эш көннән дә ким һәм 40 эш көненнән дә артык булмаган аралыкта дип билгеләнә.

Боерык проекты килештерү өчен Бүлек башлыгына юллана.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедура әлеге Регламентның 3.3.2. подпункты тарафыннан билгеләнгән процедура тәмамланган вакыттан алып ике эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен юлланган Боерык проекты.

3.4.2. Бүлек башлыгы Боерык проектын карый, аны килештерү һәм килештерү өчен аны министрның беренче урынбасарына юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән Боерык проекты.

3.4.3. Министрның беренче урынбасары Боерык проектын килештерә һәм раслау өчен министрга юллый.

Әлеге Регламентның 3.4.2. һәм 3.4.3. подпунктлары тарафыннан билгеләнгән процедура аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кул кую өчен министрга юлланган Боерык проекты.

3.4.4. Министр Боерыкка кул куя һәм теркәү өчен Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлегенә юллый.

Процедура нәтиҗәсе: кул куелган һәм теркәү өчен юлланган Боерык.

3.4.5. Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Боерыкны терки һәм үтәү өчен Бүлеккә кире кайтара.

Әлеге Регламентның 3.4.4. һәм 3.4.5. подпунктлары тарафыннан билгеләнгән процедура аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән Боерык.

3.4.6. Бүлек белгече Боерыкны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедура аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап ике эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган Боерык.

3.5. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.5.1. Гариза бирүченең вәкиле Бүлеккә шәхсән килеп язмача яки почта аша тапшырылуы турында белдерү хезмәтен кулланып заказлы хат ярдәмендә әлеге Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документлар белән бергә гариза бирә (җибәрә).

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен шартлар булмаган очракта Бүлек белгече Гариза бирүчегә гариза бирү ысулына бәйле рәвештә: я алу турында белдерү хезмәтен кулланып почта аша заказлы хат яки электрон почта ярдәмендә гариза һзм аның белән бергә тапшырылган документларны кабул итеп алган көнен күрсәтеп, аларның исемлеге күчермәсен бирә яки җибәрә, һәм Гариза бирүче гаризасын һәм документларын оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлегенә юллый.

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен шартлар булган очракта, Бүлек белгече Гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен киртә булып торган сәбәпләр барлыгы турында хәбәр җиткерә һәм аңа, документларны кабул итүдән баш тартуга сәбәп булып торган ачыкланган очракны язмача аңлатып, документларны кире кайтара (юллый).

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедура гариза кергән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм Министрлыкның оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлегенә юлланган гариза һәм документлар, шулай ук Гариза бирүчегә юлланган гариза һәм аның белән бергә тәкъдим ителгән документлар керү турындагы билгеләмәле исемлек күчермәсе яки Гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.5.2. Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече гаризаны терки һәм үтәү өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

3.6. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү бердәм системасы (алга таба – ВЭХБС) аша дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларга ия булган органнарга ведомствоара мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү.

3.6.1. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү бердәм системасы ярдәмендә электрон формада Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРЮЛ) Федераль салым идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә мәгълүмат бирү турында мөрәҗәгать юллый.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар гариза теркәлгән көннән алып бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: мәгълүмат бирүне сорап мөрәҗәгать итү.

3.6.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү бердәм системасы кергән сорау нигезендә мәгълүмат бирүчеләр белгечләре закон тарафыннан билгеләп куелган вакыт эчендә соралган документларны (Юридик затларның бердәм федераль реестрыннан өземтәне) тәкъдим итәләр.

3.6.3. Бүлек белгече тәкъдим ителгән мәгълүмат нигезендә:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 6 апрелендә кул куелган «Регионнардагы иҗтимагый оешмаларга регионнардагы спорт федерацияләре статусы бирү максаты белән дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча комиссия төзү турында» 225 номерлы боерыгы нигезендә эшли торган регионнардагы иҗтимагый оешмаларга регионнардагы спорт федерацияләре статусы бирү максаты белән дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча комиссиягә (алга таба – Комиссия) Гариза бирүченең документларын Комиссия утырышында карау мөмкинлеге турында бәяләмә әзерли һәм Комиссиягә юллый;

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләр булганда һәм документларны кире кайтарган чакта Бүлек белгече дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту һәм кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп документларны кире кайтару, шулай ук документларны кире кайтару өчен нигез булып торган сәбәпләрне юкка чыгарганнан соң яңадан гариза бирү мөмкинлеге турында министр (яки вәкаләтләр бирелгән зат) имзасы белән хат әзерли.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедура аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен Комиссиягә юлландырылган бәяләмә;

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта – министрга (вәкаләтләр бирелгән затка) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту һәм документларны кире кайтаруның сәбәпләрен күрсәткән хат проекты, шулай ук документларны кире кайтару өчен нигез булып торган сәбәпләрне юкка чыгарганнан соң яңадан гариза бирү мөмкинлеге турында хат проекты.

3.6.4. Гаризаны яңадан биргән очракта әлеге Регламентның 3.5.1., 3.5.2. подпунктлары тарафыннан каралган процедуралар тормышка ашырыла.

3.7. Регионнардагы спорт федерацияләренә дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча Комиссия утырышын үткәрү, Комиссия утырышын үткәрү турында беркетмә төзү.

3.7.1. Комиссия Рәисе Комиссия утырышы көнен билгели.

Комиссия сәркатибе шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша Гариза бирүчегә Комиссия утырышы көне турында хәбәр җиткерә.

Әлеге Регламентның 3.7.1. подпункты тарафыннан билгеләнгән процедуралар гариза һәм документларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән алып өч эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Комиссия утырышы көнен билгеләү, Гариза бирүчегә мәгълүмат җиткерү.

3.7.2. Комиссия утырышы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 6 апрелендә кул куелган «Регионнардагы иҗтимагый оешмаларга республика спорт федерацияләре статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча Комиссия төзү турында» 225 номерлы боерыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

Әлеге Регламентның 3.7.2. подпункты тарафыннан билгеләнгән процедуралар Министрлыкның регионнардагы иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясе үткәрүне игълан итү турында боерыгында билгеләнгән Гариза бирүче тарафыннан документлар тапшыру вакыты тәмамланган көннән алып 40 эш көненнән дә соңга калмыйча тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Комиссия утырышы беркетмәсе.

3.8. Регионнардагы иҗтимагый оешмасына дәүләт аккредитациясе үткәрү һәм аңа республика спорт федерациясе бирү турында боерык чыгару яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хат.

3.8.1. Бүлек Белгече Комиссия утырышында кабул ителгән тәкъдим рәвешендәге карар нигезендә:

регионнардагы иҗтимагый оешмасына дәүләт аккредитациясе үткәрү һәм аңа республика спорт федерациясе бирү турында боерык проектын (алга таба – Аккредитацияләү турында боерык проекты) яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хат проекты (алга таба – баш тарту турында хат проекты) әзерли;

аккредитацияләү турында Боерык проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.7.2. подпункты тарафыннан билгеләнгән процедуралар тәмамланган көннән алып бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен юлланган аккредитацияләү турында Боерык проектын яки баш тарту турында хат проекты.

3.8.2. Бүлек башлыгы аккредитацияләү турында Боерык проектын яки баш тарту турында хат проектын карый, килештерә һәм килештерү өчен аны министр урынбасарына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министр урынбасарына юлланган аккредитацияләү турында Боерык проектын яки баш тарту турында хат проекты.

3.8.3. Министр урынбасары аккредитацияләү турында Боерык проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерә һәм раслау өчен министрга юллый.

Әлеге Регламентның 3.8.2. һәм 3.8.3. подпунктлары белән билгеләнә торган процедуралар аңа кадәр килгән процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: аккредитация турында боерык проекты яки баш тарту турында министрга кул куярга җибәрелгән хат проекты.

3.8.4. Министр карар кабул итә һәм регионнардагы иҗтимагый оешманың дәүләт аккредитациясе һәм аңа республика спорт федерациясе статусын бирү турында боерыкка яки регионнардагы иҗтимагый оешмасына дәүләт аккредитациясеннән баш тарту турында хатка имза куя.

Процедура нәтиҗәс: кул куелган регионнардагы иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрү һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү турында боерык (алга таба – Боерык) яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хат.

3.8.5. Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Боерык яки соңыннан Гариза бирүчегә юлланачак дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хатны терки.

Әлеге Регламентның 3.8.4. һәм 3.8.5. подпунктлары тарафыннан билгеләнгән процедуралар аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: теркәлгән Боерык яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хат.

3.8.6. Бүлек белгече:

Расланган боерыкны Министрлык сайтына урнаштыра;

Гариза бирүчегә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында хәбәр итә яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хат юллый.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедура аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап дүрт эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: сайтта урнаштырылган боерык, гариза бирүчегә ирештерелгән хәбәр.

3.9. Россия Федерациясе Спорт министрлыгына республика спорт федерациясенә дәүләт аккредитацияләве белән бәйле мәгълүмат һәм документлар тәкъдим итү.

3.9.1. Бүлек белгече документлар пакетын әзерли (республика спорт федерациясе документларын карау турында Министрлык гаризасы, Министрлыкның республика спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында боерыгы, республика спорт федерациясе документлары) һәм аны республика спорт федерациясе турындагы мәгълүматны гомумроссия һәм

регионнардагы аккредитацияләнгән спорт федерацияләре реестрына (алга таба – Реестр) кертү өчен Россия Федерациясе Спорт министрлыгына юллый.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап биш эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Россия Федерациясе Спорт министрлыгына юлланган документлар.

3.9.2. РФ Спорт министрлыгы регионнардагы спорт федерациясе турында мәгълүматны Реестрга кертү турында карар кабул итә һәм боерык чыгара яки Министрлыкка, сәбәпләрен күрсәтеп, мәгълүматны Реестрга кертүдән баш тарту турында хәбәр җибәрә.

3.9.3. Регионнардагы спорт федерациясе турында мәгълүматны Реестрга кертү турында РФ Спорт министрлыгы боерыгын РФ Спорт министрлыгының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыргач яисә РФ Спорт министрлыгыннан Министрлыкка Реестрга мәгълүмат кертүдән баш тарту турында хәбәр килеп җиткәннән соң, Бүлек белгече дәүләт аккредитациясе узу турында документ (таныклык) (1нче кушымта) яки, сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хат Проекты әзерли.

Процедуралар нәтиҗәсе: әзерләнгән дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хат проекты.

3.9.4. Бүлек белгече дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хат Проектын килештерә һәм килештерү өчен министр урынбасарына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хат Проекты.

3.9.5. Министр урынбасары дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хат Проектын килештерә һәм кул куяр өчен министрга юллый.

Процедура нәтиҗәсе: кул куяр өчен министрга юлланган дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хат Проекты.

3.9.6. Министр дәүләт аккредитациясе турында документка (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хат Проектына кул куя.

Процедура нәтиҗәсе: кул куелган дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хат.

3.9.7. Бүлек белгече дәүләт аккредитациясе турындагы документны (таныклыкны) дәүләт аккредитациясе турында документлар (таныклыклар) бирү реестрында терки һәм, Гариза бирүче республика спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында документ (таныклык) биргән өчен дәүләт пошлинасы түләгәннән соң, аны Гариза бирүчегә тапшыра (юллый), яки Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлеге Белгече дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турындагы хатны терки һәм Гариза бирүчегә җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.9.3. – 3.9.7. подпунктлары тарафыннан билгеләнгән процедуралар РФ Спорт министрлыгының республика спорт федерациясе турындагы мәгълүматны гомумроссия һәм регионнардагы аккредитацияләнгән спорт федерацияләре кертү турындагы боерыгын РФ Спорт министрлыгының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырган көннән алып унбиш эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Гариза бирүчегә бирелгән (юлланган) дәүләт аккредитациясе үткәрү турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хат.

3.10. Дубликат бирү һәм дәүләт аккредитациясе үткәрү турындагы документны (таныклыкны) яңадан теркәү.

3.10.1. Дәүләт аккредитациясе үткәрү турындагы документны (таныклыкны) югалткан очракта республика спорт федерациясе бу турында Министрлыкка хәбәр итә һәм дәүләт аккредитациясен узу турындагы документның (таныклыкның) дубликатын бирү турында гариза тапшыра. Гариза бирүченең вәкиле шәхсән, тапшырылуы турында белдерү хезмәтен кулланып почта аша заказлы хат ярдәмендә яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә дәүләт аккредитациясе документының (таныклыгының) дубликатын бирү турында ирекле рәвештә язылган гариза тапшыра (юллый).

3.10.2. Бүлек белгече дәүләт аккредитациясен узу турындагы документның (таныклыкның) дубликатын әзерли, аны юридик эш секторында раслата һәм аны Гариза бирүчегә юллый.

Дәүләт аккредитациясе узу турында документның (таныклыкның) дубликатын бирү Министрлыкка дәүләт аккредитациясе узу турында таныклык дубликатын бирү турында гариза кергәннән башлап 30 эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Гариза бирүчегә бирелгән дәүләт аккредитациясе узу турында документ (таныклык) дубликаты.

3.10.3. Республика спорт федерациясенең атамасы яки аның юридик адресы үзгәргән очракта Гариза бирүче 15 эш көне дәвамында шәхсән яки Вәкиле аша, яисә тапшырылуы турында белдерү хезмәтен кулланып почта аша заказлы хат ярдәмендә әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән документлар, шулай ук дәүләт аккредитациясе үткәрү турында моңа кадәр бирелгән документ (таныклык) белән бергә дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклыкны) яңадан теркәү турында гариза (ирекле рәвештә) тапшыра (юллый).

3.10.4. Дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклыкны) яңадан теркәү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү, документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктының 3 подпунктына туры килүен тикшерү, документлар әлеге Регламентның 2.5 пунктының 3 подпункты таләпләренә туры килмәгән очракта дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында карар кабул иткәндә Гариза бирүчегә хәбәр итү процедуралары, шулай ук ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү бердәм системасын кулланып дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган мәгълүматлар тәкъдим итү турында сорауны

юллау процедурасы әлеге Регаментның 3.5. һәм 3.6. подпунктлары нигезендә тормышка ашырыла.

3.10.5. Бүлек белгече ведомствоара документлар әйләнеше кысаларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документлар булган дәүләт органыннан килгән мәгълүмат, дәүләт аккредитациясе турындагы документны (таныклыкны) яңадан теркәү турында гариза һәм аның белән бергә тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук Министрлыкта булган дәүләт аккредитациясе турындагы документны (таныклыкны) Гариза бирүчегә тапшыру белән бәйле мәгълүмат нигезендә:

Министрлыкның Гариза бирүчегә дәүләт аккредитацияләве үткәрү турында боерыгына (алга таба – Министрлык Боерыгы) үзгәрешләр кертү турында карар кабул итә;

Министрлык Боерыгы проектын әзерли яки Гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту һәм кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп документларны кире кайтару турында хат проекты (дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта) әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрә;

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар гариза теркәлгән көннән алып ике эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерү өчен юлланган Министрлык Боерыгы проекты яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында Гариза бирүчегә аталган хат проекты.

3.10.6. Бүлек башлыгы Министрлык Боерыгы проектын яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында Гариза бирүчегә аталган хат проектын килештерә һәм килештерү өчен министр урынбасарына җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан расланган Министрлык Боерыгы проекты яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында Гариза бирүчегә аталган хат проекты.

3.10.7. Министр урынбасары Министрлык Боерыгы проектын яки Гариза бирүчегә аталган хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы хат проектын килештерә һәм кул куяр өчен министрга юллый.

Әлеге Регламентның 3.10.6. һәм 3.10.7. подпунктлары тарафыннан билгеләнгән процедуралар аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кул куяр өчен министрга юлланган Министрлык Боерыгы проекты яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында Гариза бирүчегә аталган хат проекты.

3.10.8. Министр Министрлык Боерыгына яки Гариза бирүчегә аталган хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы хатка кул куя.

Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Министрлык Боерыгын терки һәм Бүлеккә кире кайтара, яисә дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хатны терки һәм Гариза бирүчегә юллый.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедура документларның кул куярга кергән көнендә үк башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Министрлык Боерыгы яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән

баш тарту турында Гариза бирүчегә аталган хат.

3.10.9. Бүлек белгече Министрлык боерыгын Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра һәм Министрлыкның рәсми сайтында урын алган аккредитацияләнгән федерацияләр исемлегенә үзгәрешләр кертә.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедура аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап ике эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган Министрлык боерыгы һәм Министрлык сайтында урын алган исемлеккә кертелгән үзгәрешләр.

3.10.10. Бүлек белгече дәүләт аккредитациясе узу турында яңа документны (таныклыкны) рәсмиләштерә, дәүләт аккредитациясе узу турындагы яңа документны (таныклыкны) дәүләт аккредитациясе турындагы документларны (таныклыкларны) бирүне теркәү журналында терки һәм дәүләт аккредитациясе турындагы яңа документны (таныклыкны) Гариза бирүчегә тапшыра (юллый).

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнә торган процедура аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап ике эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт аккредитациясе турында Гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) яңа документ (таныклык).

3.10.11. Бүлек белгече Россия Федерациясе Спорт министрлыгына регионнардагы спорт федерациясенә бирелгән дәүләт аккредитацияләве турындагы документны (таныклыкны) яңадан теркәү турында хәбәр җибәрә.

Әлеге подпункт тарафыннан билгеләнгән процедура аңа кадәр килгән процедура тәмамланган көннән башлап өч эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Россия Федерациясе Спорт министрлыгына регионнардагы спорт федерациясенә бирелгән дәүләт аккредитацияләве турындагы документны (таныклыкны) яңадан теркәү турында җибәрелгән хәбәр.

3.11. Дәүләт хезмәте КФҮтә, КФҮнең читтә урнашкан эш урыны аша күрсәтелми.

3.12. Техник хаталарны төзәтү.

3.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документта техник хата ачыкланган очракта Гариза бирүче Бүлеккә түбәндәгеләрне китерә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (ирекле рәвештә);

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак Гариза бирүчегә тапшырылган дәүләт аккредитациясе турында техник хата ачыкланган документ (таныклык).

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматта техник хатаны төзәтү турындагы гариза Гариза бирүче (аның вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән, яисә почта юлламасы, яисә электрон почта ярдәмендә, яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша бирелә.

3.12.2. Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлегенең документларны кабул итү өчен җаваплы булган белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итеп ала, аның белән бергә тапшырыла торган документлар белән гаризаны терки һәм аны бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә карау өчен җибәрелгән кабул итеп алынган һәм теркәлгән гариза.

3.12.3. Бүлек белгече документларны карый һәм, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны тормышка ашыра һәм төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән, имза куйдырып, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хата булган документның оригиналын алганнан соң, бирә, яки гариза бирүче адресына почта юлламасы белән (электрон почта аша) техник хата булган документның оригиналын Бүлеккә тапшырган очракта документны алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хатаны ачыклаганнан соң яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алган вакыттан башлап өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) документ.

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшерү тәртибе һәм рәвеше

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү үз эченә түбәндәгеләрне ала: Гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм юкка чыгару, шикаятьләрне карау, тикшерүләр үткәрү, Гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләре буенча карарлар кабул итү һәм җавап әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата карарлар әзерләү.

Административ процедураларны башкаруны үтәүне тикшерү формалары булып түбәндәгеләр тора:

эш башкаруны алып бару;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен юллау вакытларын һәм тәртибен саклау.

Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (план буенча башкарылган эшләр нигезендә тормышка ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

Әлеге Регламентның 3 нче бүлеге тарафыннан билгеләнгән административ процедураларны башкаруны тикшерүне тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәткән һәм карарлар кабул иткән чакта министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедуралар тарафыннан билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген агымдагы тикшерү министр урынбасары тарафыннан тормышка ашырыла.

4.3. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Әлеге Регламентны үтәүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан тикшерү дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеге һәм дәүләт хезмәтен бирү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә тормышка ашырыла.

## 5. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затлары һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәте алучыларның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи затының, яисә Министрлыкның дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата судка шикаять бирү хокукы бар.

Шикаять Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрына, ә Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры карарлары һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата шикаять язылган очракта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында Гариза бирүче соравын теркәү вакытын бозган очракта;
- дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозганда;
- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны таләп иткәндә;
- Гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында

каралган документларны кабул итүдән баш тарткан чакта;

- әгәр баш тарту өчен нигезләмәләр федераль законнар һәм аларга бәйле рәвештә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә Гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп иткән очракта;

- дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлык, дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тартканда яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозган чакта.

5.2. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mdms.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi.tatar.ru/), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләре) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында Гариза бирүченең үзеннән кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне дәвамында. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты Гариза бирүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарткан очракта, яисә андый төзәтүләрне билгеләнгән вакытны бозу буенча шикаять биргән очракта – аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның вазыйфаи затының яки карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата шикаять бирелә торган дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта), тору урыны турында белешмә, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның вазыйфаи заты, яки дәүләт хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның вазыйфаи заты, яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамьсезлеге) белән килешмәү өчен нигез булып торган дәлилләр.

5.5. Шикаять белән бергә анда күрсәтелгән хәлләрне раслый торган документ күчермәләрен дә тәкъдим итәргә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аның белән бергә бирелә торган документлар исемлеге тәкъдим ителә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча министр түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында түләтү каралмаган акча чараларын кире кайтару формасында, шулай ук башка формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге Регламентның 1нче һәм 2нче подпунктларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килә торган көннән соңга калмыйча, Гариза бирүчегә язмача яки Гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап юллана.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә аны карауның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләре булган вазыйфаи зат тиз арада булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы**

Республика спорт федерациясе
статусына ия булуны раслый торган
дәүләт аккредитациясен узу турындагы
ТАНЫКЛЫК

____________ №
____________
(бирелү датасы) (цифрлар белән)

________________________________________________________________
(иҗтимагый оешманың тулы атамасы, оештыру-хокукый формасын да кертеп)

________________________________________________________________
(иҗтимагый оешманың төп дәүләт теркәве номеры)

________________________________________________________________
(иҗтимагый оешманың адресы (урнашкан урыны))

________________________________________________________________
(спорт төренең Спорт төрләренең бөтенроссия реестры нигезендәге атамасы, спорт төренең номер-коды)
спорт төре буенча аккредитацияләнде.

______________________________ дәүләт аккредитациясе турында карар нигезендә
(документның реквизитлары)

________________________дан ________________________кадәр республика спорт
(дата) (дата)
федерациясе статусы бирелә һәм ____________________________________________
(бөтенроссия һәм аккредитацияләнгән регионнардагы спорт федерацияләре реестры нигезендә номер-код)

номер-код астында бөтенроссия һәм аккредитацияләнгән регионнардагы спорт федерацияләренең реестрына кертелә.

__________________________
(Министр (имза) (инициаллар, фамилия)

М.У.

2 нче кушымта

үрнәк

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре
һәм спорт министрлыгы

**ГАРИЗА**

дәүләт аккредитациясен игълан итү турында 20___елның "______"_____________________ номерлы боерыгы нигезендә регионнардагы иҗтимагый оешмага _________ спорт төре буенча дәүләт аккредитациясе үткәрү турында

| Спорт төренең СТБР нигезендәге атамасы | Спорт төренең СТБР нигезендәге номер-коды | Регионнардагы иҗтимагый оешманың, оештыру-хокукый формасын да кертеп, тулы атамасы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Регионнардагы спорт федерациясенең юридик адресы

| | |
|---|---|
| Кушымта: | 1. Регионнардагы иҗтимагый оешма тарафыннан расланган устав күчермәләре (ике нөсхәнең берсе нотариус тарафыннан раслана): иҗтимагый оешманы төзү, аның уставын раслау һәм җитәкче органнарны һәм тикшерү-ревизия органын формалаштыру турында оештыру съезды (конференциясе) яки гомуми җыелыш беркетмәсе, юстиция органында теркәү турында таныклык, 2 нөсхәдә ___биттә. |
| | 2. Регионнардагы спорт федерациясенең даими эшли торган җитәкче органы составына керә торган затлар исемлеге һәм әлеге җитәкче органны сайлау турында беркетмә күчермәсе 2 нөсхәдә ____ биттә. |
| | 3. Регионнардагы спорт федерациясе әгъзалары булып торучы затлар исемлеге, 2 нөсхәдә ___биттә. |
| | 4. Регионнардагы спорт федерациясенең гомумроссия спорт федерациясендә әгъза булып торуын раслый торган документ күчермәсе, 1 нөсхәдә ___ биттә.[1] |
| | 5. Гомумроссия спорт федерациясенең регионнардагы иҗтимагый оешманың дәүләт аккредитациясенә язмача ризалыгы (329-ФЗ номерлы федераль законның 13 маддәсенең 5 өлеше) төп нөсхә һәм күчермәсе ___биттә.[2] |
| | 6. Россия Федерациясе субъекты җыелма спорт командасы составына кертү өчен спортчыларны сайлап алу тәртибе турында нигезләмә проекты 1 нөсхәдә __биттә. |
| | 7. Спорт төрен үстерү программасы 1 нөсхәдә __биттә. |
| | 8. Регионнардагы иҗтимагый оешманың эшчәнлеген финанслау чыганаклары турында белешмә 1 нөсхәдә __биттә. |
| | 9. Дәүләт аккредитациясе турында гариза бирү алдыннан 1 ел эчендә регионнардагы иҗтимагый оешма уздырган регионнардагы ярышлар беркетмәләре күчермәләре 1 нөсхәдә __биттә. |
| | 10. Гариза, шулай ук югарыда саналган документлар һәм белешмәләр белән электрон мәгълүмат йөртүче (CD диск, флэш туплаучы) – 1 данә. |

(РИО җитәкчесе вазифасы ) (имза) (И.Аи. Фамилия)

"______"_______________
20___ел М.У.

[1] – регионнардагы иҗтимагый оешма бөтенроссия спорт федерациясе әгъзасы булып торган очракта бирелә.

[2] – әгәр регионнардагы иҗтимагый оешма СТБРның беренче яки өченче өлешенә кертелгән спорт төре буенча дәүләт аккредитациясенә гариза бирсә, әлеге документ тапшырылмый.

3 нче кушымта

Регионнардагы иҗтимагый оешма (РИО) әгъзалары булып торган затлар
ИСЕМЛЕГЕ

______________________________________________________________

(регионнардагы иҗтимагый оешманың, оештыру-хокукый формасын да кертеп, тулы атамасы

[          ] торышына карата

(тутыру датасы – көн, ай, ел)

**Физик затлар**

| №№ | Фамилия, исеме, атасының исеме |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| … | |

**Иҗтимагый берләшмәләр – юридик затлар**

| №№ | Иҗтимагый берләшмәнең – юридик затның, оештыру-хокукый формасын да кертеп, тулы атамасы |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| … | |

______________________ ______________________ ______________________

(РИО җиткчесенең вазифасы) (имза) (И.Аи. Фамилия)

"_____"___________20___ел

М.П.

4 нче кушымта

Регионнардагы иҗтимагый оешманың (РИО) җитәкче органнарының персональ составы турында
**БЕЛЕШМӘЛӘР**

______________________________________________________________________________

(иҗтимагый оешманың, оештыру-хокукый формасын да кертеп, тулы атамасы

[ ] торышына карата
(тутыру датасы – көн, ай,ел)

______________________________________________________________________________

(РИО уставы нигезендә даими рәвештә эшли торган җитәкче органның атамасы – идарә, президиум, башкарма комитет һ.б.)

Җитәкче органның вәкаләтләре вакыты[1]: [ ] нан [ ] кадәр
(көн, ай, ел) (көн, ай, ел)

| №№ | Фамилия, Исем, Атасының исеме (тулысынча) | Җитәкче органдагы вазыйфасы | Туган көне (көн, ай, ел) | Паспорт сериясе, номеры, бирү датасы һәм паспорт бирүче орган атамасы | Даими яшәү урыны адресы[2], телефон номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| … | | | | | |

_____________________ _____________________ _____________________ "____"__________20__ел М.У.
(РСФ җитәкчесе вазыйфасы) (Имза) (И.Аи. Фамилия)

[1] - РИО уставы нигезендә соңгы хисап-сайлау конференциясен үткәргән көннән башлап РИО ның гамәлдәге җитәкче органының вәкаләтләре вакыты күрсәтелә.
[2] - паспорт мәгълүматлары нигезендә тутырыла.

5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яшьләр
эшләре һәм спорт министрлыгына

**Бөтенроссия спорт федерациясенең региондардагы иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясен үткәрүне килештерүе**

Региондардагы иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәләренә (региондардагы бүлекчәләре) аларга региондардагы спорт федерациясе статусын бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү тәртибенең 7 пункты «г» подпункты һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2014 елның 1 августында кул куелган 663 номерлы боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 2014 елның 5 августында 33458 номеры белән теркәлгән) белән расланган региондардагы спорт федерациясе статусына ия булуын раслый торган дәүләт аккредитациясе булуы турында документ формасы нигезендә

____________________________________________________________

гомумроссия спорт федерациясенең тулы атамасы

____________________________________________________________

оештыру-хокукый формасын, ОГРН, Гомумроссия һәм аккредитацияләнгән региондардагы спорт федерацияләренең реестры буенча номеры, һәм, әгәр документлар реквизитларында күрсәтелмәгән булса, почта адресы, телефонын да кертеп,

____________________________________________________________

региондардагы иҗтимагый оешманың тулы атамасы

____________________________________________________________

оештыру-хокукый формасын, почта адресы, телефонын да кертеп,

«__________________________________________________________»

СТБР буенча спорт төренең атамасы

спорт төре буенча дәүләт аккредитациясен яраклаштыра.

Әлеге килештерү бер ел эчендә аккредитация алу өчен бирелә.

__________________________

документ реквизитларында күрсәтелмәгән булса, дата


| ________________________ | ______________ | __________________ |
|---|---|---|
| гомумроссия спорт федерациясе җитәкчесенең вазыйфасы атамасы | имза, мөһер | инициаллар, фамилия |


________________________


Үтәүченең Ф.И.Аи., телефон

6 нчы кушымта

Регионнардагы иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрү һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




Белгеч
ВЭХБС буенча сорау кирәклеген билгели.
Зарури булган
юк
әйе
Белгеч документлар кабул итүдән баш тарту турында хат проектын әзерли
(5 эш көне)
Белгеч
Документларны тикшерә. Хисап эшен формалаштыра һәм Комиссиягә җибәрә
(1 эш көне)
Белгеч
Мәгълүматлар куючыларга сораулар әзерли һәм ВЭХБС буенча җибәрә
(1 эш көне)
Бүлек башлыгы һәм министр урынбасары
Хат проектын килештерә
(1 эш көне)
Хисап эше
Җибәрелгән сораулар
Комиссия секретаре
Утырыш вакытын билгели һәм гариза бирүчегә хәбәр итә
(1 эш көне)
Мәгълүматлар куючылар документлар (белешмәләр) җибәрә
(5 эш көне)
Министр
Хатка кул куя.
Эш башкару бүлеге белгече
Гариза бирүчегә хат һәм документларны җибәрә
(1 эш көне)
Документлар
Гариза бирүчегә утырыш датасы турында хәбәр итү
Комиссия карар кабул итә
(утырыш көнендә)
Беркетмә
Гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар
Белгеч
Дәүләт аккредитациясе турында боерык яисә дәүләт аккредитациясен үткәрүдән баш тарту турында хат әзерли
(3 эш көне)
Кабул ителгән карарга бәйле
Аккредитация
Баш тарту
Боерык проекты
Баш тарту турында хат проекты
Бүлек башлыгы һәм министр урынбасары
Боерык проектын яисә баш тарту турындагы хат проектын килештерә
(1 эш көне)
Килештерелгән боерык проекты
Баш тарту турында килештерелгән хат
Министр
Боерык яки баш тарту турындагы хатка кул куя
(1 эш көне)
Имзаланган боерык
Баш тарту турында кул куелган хат


Эш башкару бүлеге белгече
Боерыкны терки
(1 эш көне)
Белгеч
Боерыкны сайтка
урнаштыра
(3 эш көне)
Кул куелган һәм сайтта урнаштырылган боерык
Эш башкару бүлеге белгече
Баш тарту турындагы хатны терки һәм гариза бирүчегә юллый
(1 эш көне)
Белгеч
Документлар пакетын әзерли һәм РФ Спорт министрлыгына җибәрә.
(5 эш көне)
РФ Спорт министрлыгына юлланган документлар
РФ Спорт министрлыгы
Регионнардагы спорт федерациясе турындагы мәгълүматны гомумроссия һәм регионнардагы аккредитацияләнгән спорт федерацияләре реестрына кертү турында карар кабул итә һәм боерык чыгара яисә ТР ЯЭСМ мәгълүматларны реестрга кертүдән баш тарту турында, сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәр җиткерә
РФ Спорт министрлыгы тарафыннан кабул ителгән карарга бәйле рәвештә
Бүлек белгече
Дәүләт аккредитациясе турындагы документны (таныклыкны) рәсмиләштерә
(12 эш көне)
Бүлек белгече
Хезмәтне күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли
(12 эш көне)
Таныклык проекты
Баш тарту турында хат проекты
Бүлек башлыгы һәм Министр урынбасары
Боерык проектын яки таныклык проектын килештерә
(1 эш көне)
Бүлек башлыгы һәм Министр урынбасары
Баш тарту турындагы хатны килештерә
(1 эш көне)
Таныклыкның килештерелгән проекты
Баш тарту турында килештерелгән хат проекты
Министр
Таныклыкка кул куя
(1 эш көне)
Министр
Баш тарту турындагы хатка кул куя
(1 эш көне)
Имзаланган таныклык
Кул куелган баш тарту турындагы хат
Белгеч таныклыкны тапшыра
(1 эш көне)
Эш башкару бүлеге белгече
Хатны терки һәм гариза бирүчегә җибәрә.
(1 эш көне)
Гариза бирүчегә тапшырылган дәүләт аккредитациясе узу турындагы таныклык
Гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында хатны җибәрү.

7 нче кушымта (мәгълүмат өчен)

**Регионнардагы иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәләренә (регионнардагы бүлекчәләре) аларга республика спорт федерациясе статусын бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнарның һәм вазыйфаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы

| Вазыйфасы, ФИАи | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр Леонов Владимир Александрович | 222-81-01(02) | Vladimir.Leonov@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары Шәйхетдинов Хәлил Хәмит улы | 222-81-09 | Halil.Shayhutdinov@tatar.ru |
| Спорт төрләрен үстерү бүлеге башлыгы Вафин Раиф Ришат улы | 222-81-44 | Raif.Vafin@tatar.ru |
| Спорт төрләрен үстерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты Горбунов Константин Юрьевич | 222-81-46 | Konstantin.Gorbunov@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфасы, ФИАи | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен булдыру мәсьәләләре буенча бүлек башлыгы Шакирова Гүзәл Рәис кызы | 264-77-84 | Guzel.Shakirova@tatar.ru |